**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 11 июль

№ 470

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 апрель, 237 нче; 2015 ел, 15 апрель, 255 нче; 2015 ел, 18 май, 354 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 848 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 нче пунктның унберенче, ундүртенче, унтугызынчы, егерменче абзацларын төшереп калдырырга;

2.1 нче пунктта:

2.1.1 нче пунктчада:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәр категориясе өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) реализацияләүдән табышның чик мәгънәләре турында» 2015 ел, 13 июль, 702 нче карары;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәр категориясе өчен эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алынган керемнең чик мәгънәләре турында» 2016 ел, 4 апрель, 265 нче карары (2016 елның 1 августыннан гариза бирүче эшмәкәрлек субъектлары өчен).»;

түбәндәге эчтәлекле 2.1.4 нче пунктча өстәргә:

«2.1.4. Эшмәкәрлек субъектының әлеге Нигезләмә нигезендә элегрәк алган ярдәмгә бәйле, шул исәптән акчадан файдалану һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турындагы хисаплылыкны тапшыру буенча үтәлмәгән бурычлары булмау.»;

4.1 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«соңгы хисап датасына юридик затлар өчен бухгалтерлык хисаплылыгы (бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап) һәм индивидуаль эшмәкәрләр өчен керемнәр һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсе, агымдагы хисап чорында теркәлгән индивидуаль эшмәкәрләрдән тыш, һәм юридик затның (индивидуаль эшмәкәрнең) салым декларациясе (хисаплылыгы) (агымдагы хисап чорында теркәлгән юридик затлардан (индивидуаль эшмәкәрләрдән) тыш);»;

алтынчы абзацка «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2007 ел, 29 март, ММ-3-25/174@ боерыгы белән расланган форма буенча» сүзләрен өстәргә;

4.2 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2014 ел, 21 июль, ММВ-7-8/378@ боерыгы белән расланган форма буенча конкурс гаризасы тапшырыла торган айның беренче көне хәленә карата бирелгән һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланган, эшмәкәрлек субъектының салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмауны раслый торган салым органы белешмә кәгазе;»;

5.1 нче пунктның икенче абзацындагы беренче җөмләгә «һәм 14 эш көненнән дә ким була алмый» сүзләрен өстәргә;

5.3 нче пунктта «календарь» сүзен «эш» сүзенә алмаштырырга;

5.4 нче пунктта «эшләп бетерергә кирәк булу» сүзләрен «кертүдән баш тарту» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $5.12^1$ нче пункт өстәргә:

«$5.12^1$. Беркетмә конкурс комиссиясе утырышын үткәрү көне, вакыты һәм урыны, утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары, карап тикшерелгән гаризалар саны, субсидия суммасын һәм эшмәкәрлек субъекты теркәлгән муниципаль берәмлекне күрсәтеп, конкурс гаризаларын карап тикшерү нәтиҗәсе, бирелә торган субсидияләрнең соңгы суммасы, субсидия бирүдән баш тартылган катнашучылар буенча субсидияләрнең соңгы суммасы турындагы мәгълүматны үз эченә ала.»;

5.14 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе карары нәтиҗәләре буенча субсидия бирүдән баш тартылган гариза бирүчегә гаризасы кайтарылмый һәм Вәкаләтле оешмада билгеләнгән тәртиптә саклана.»;

5.15 нче пунктта «һәм Вәкаләтле оешма раслый торган форма нигезендә үзләре кул куйган шартнамәне Вәкаләтле оешмага кертә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Бу бүлектә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

лизингка бирүче – җәлеп ителгән акча яки үз акчасы исәбеннән лизинг алыш-бирешен тормышка ашыру барышында милеккә җиһазлар сатып алучы һәм аларны эшмәкәрлек субъектына лизинг предметы рәвешендә бирүче юридик зат. Лизингка бирүче түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

а) Россия Федерациясе резиденты статусы булу;

б) гамәлгә кую документларында төп эшчәнлек төре буларак финанс арендасына (лизингка) мөлкәт бирүгә күрсәтелү;

в) эшмәкәрлек субъектларына финанс арендасына (лизингка) мөлкәт бирү өлкәсендә кимендә өч еллык эш тәҗрибәсе булу;

г) эшмәкәрлек субъектлары белән төзелгән финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренең формалаштырылган портфеле булу, эшмәкәрлек субъектлары белән эшләү буенча махсуслаштырылган технологияләр (программалар) булу;

д) лизингка алучы – эшмәкәрлек субъектының финанс хәлен бәяләү буенча расланган методика булу;

е) соңгы хисап датасына чиста активлар кыйммәтенең уңай күләме булу (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Чиста активлар кыйммәтен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 август, 84н боерыгы белән расланган методика буенча);

ж) соңгы хисап датасына чиста активлар кыйммәте күләме – кимендә 40 млн.сум (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Чиста активлар кыйммәтен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 август, 84н боерыгы белән расланган методика буенча) яисә соңгы хисап датасына устав капиталы күләме кимендә 15 млн.сум булу;

финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча беренче кертем (аванс) – лизинг түләүләрен түләү графигында билгеләнгән һәм мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты буенча лизинг предметын фактта алган вакытка кадәр финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча эшмәкәрлек субъекты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган түләү (түләүләр).»;

7.1.1 нче пунктта «Вәкаләтле органга» сүзләрен «Вәкаләтле оешмага» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. «Җиһазлар лизингын үстерү: җиһазлар лизингы шартнамәсе (ЛИЗИНГ-ГРАНТ) буенча беренче кертемне (аванс) түләүгә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча республика карамагындагы шәһәрләрдә теркәлгән эшмәкәрләргә ярдәм итү өчен бюджет ассигнованиеләре лимиты бу чара буенча ассигнованиеләрнең гомуми күләменең кимендә иң күбе 50 процентын тәшкил итә.

Республика карамагындагы шәһәрләрдә теркәлгән эшмәкәрләргә ярдәм итү өчен ассигнованиеләр тулы күләмдә таләп ителмәгән очракта, алар Татарстан

Республикасының башка административ-территориаль берәмлекләрендә теркәлгән эшмәкәрлек субъектлары файдасына бүлеп бирелергә тиеш.»;

7.3 нче пунктның таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01.1 | Берьеллык культуралар үстерү |
| 01.2 | Күпьеллык культуралар үстерү |
| 01.3 | Үрентеләр үстерү |
| 01.4 | Терлекчелек |
| 01.5 | Катнаш авыл хуҗалыгы |
| 02.1 | Урманчылык һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге |
| 02.2 | Агач хәзерләү |
| 02.3 | Ашарга яраклы урман ресурслары, агач булмаган урман ресурслары һәм дару үләннәре җыю һәм хәзерләү |
| 03.2 | Балыкчылык |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 11 | Эчемлекләр җитештерү |
| 13 | Текстиль әйберләр җитештерү |
| 14 | Өс киемнәре җитештерү |
| 15 | Күн һәм күннән әйберләр җитештерү |
| 16 | Агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән әйберләр (җиһазлардан гайре) җитештерү, саламнан һәм үрә торган материаллардан әйберләр җитештерү |
| 17 | Кәгазь һәм кәгазь әйберләр җитештерү |
| 18 | Полиграфия эшчәнлеге һәм мәгълүмат чыганакларыннан күчермә алу |
| 20 | Химик матдәләр һәм химия продуктлары җитештерү |
| 21 | Дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар җитештерү |
| 22 | Резин һәм пластмасса әйберләр җитештерү |
| 23 | Металл булмаган башка минераль продукция җитештерү |
| 24 | Металлургия җитештерүе |
| 25 | Әзер металл әйберләр (машиналардан һәм җиһазлардан гайре) җитештерү |
| 26 | Компьютерлар, электрон һәм оптик әйберләр җитештерү |
| 27 | Электр җиһазлары җитештерү |
| 28 | Башка төркемчәләргә кертелмәгән машиналар һәм җиһазлар җитештерү |
| 29 | Автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерү |
| 30 | Башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү |
| 31 | Җиһазлар җитештерү |
| 32 | Башка әзер әйберләр җитештерү |
| 38 | Калдыклар җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чимал эшкәртү |
| 39 | Пычратулардан салынган зыяннарны бетерү өлкәсендә хезмәтләр |

| | |
|---|---|
| | күрсәтү һәм калдыкларны юкка чыгаруга бәйле булган башка хезмәтләр күрсәтү |
| 49.31 | Коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге: шәһәр эчендә һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү (табигый газ (метан) белән эшли торган автотранспорт чаралары сатып алынган очракта) |
| 49.41 | Йөк автомобиль транспорты эшчәнлеге (табигый газ (метан) белән эшли торган автотранспорт чаралары сатып алган очракта)»; |

7.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Субсидияләр түбәндәгеләргә бирелә:

а) конкурс гаризасын биргән вакытка теркәлү вакытлары 1 елдан кимрәк булган эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – эшчәнлекләрен башлап җибәрүче эшмәкәрлек субъектлары), җиһазлар лизингы шартнамәсен төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә максатчан чыгымнарны өлешле финанслау шартларында лизинг шартнамәсе суммасының 45 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 1 млн.сумнан арттык түгел;

б) конкурс гаризасын биргән вакытка теркәлү вакытлары 1 елдан артып киткән эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – эшләп торучы эшмәкәрлек субъектлары) лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен кертү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг шартнамәсе суммасының 30 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 3 млн.сумнан арттык түгел;

в) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2014 елда Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында» 2014 ел, 24 март, б-65/2 нче боерыгы белән расланган «2014 елда Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасы буенча конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында» 2015 ел, 12 март, б-37/2 нче боерыгы белән расланган «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасы буенча конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эшләрен башлап җибәрүче фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасын раслау турында» 2015 ел, 17 март, б-50/2 нче боерыгы белән расланган «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эшләрен башлап җибәрүче фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасы буенча конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен кертү

буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг шартнамәсе суммасының 70 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 1 млн.сумнан арттык түгел;

г) ит продукциясе җитештерү өчен терлек, кош-корт сую цехларын төзү һәм үстерү проектларын тормышка ашыра торган эшләп торучы эшмәкәрлек субъектларына, шулай ук эшләп торучы эшмәкәрлек субъектлары – авыл хуҗалыгы кооперативларына лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен кертү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг шартнамәсе суммасының 50 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 3 млн.сумнан арттык түгел.»;

7.6 нчы пунктта «Вәкаләтле орган» сүзләрен «Вәкаләтле оешма» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.8 нче пункт өстәргә:

«7.8. Субсидия бирү өчен документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган булырга тиеш, мөһер белән расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш, бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре эшмәкәрлек субъектының имзасы һәм мөһере (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта) белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш.»;

8.1 нче пунктның таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «02.2 | Агач хәзерләү |
| 02.3 | Ашарга яраклы урман ресурслары, агач булмаган урман ресурслары һәм дару үләннәре җыю һәм хәзерләү |
| 03.2 | Балыкчылык |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 11 | Эчемлекләр җитештерү |
| 13 | Текстиль әйберләр җитештерү |
| 14 | Өс киемнәре җитештерү |
| 15 | Күн һәм күннән әйберләр җитештерү |
| 16 | Агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән әйберләр (җиһазлардан гайре) җитештерү, саламнан һәм үрә торган материаллардан әйберләр җитештерү |
| 17 | Кәгазь һәм кәгазь әйберләр җитештерү |
| 20 | Химик матдәләр һәм химия продуктлары җитештерү |
| 21 | Дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар җитештерү |
| 22 | Резин һәм пластмасса әйберләр җитештерү |
| 23 | Металл булмаган башка минераль продукция җитештерү |
| 24 | Металлургия җитештерүе |
| 25 | Әзер металл әйберләр (машиналардан һәм җиһазлардан гайре) җитештерү |
| 26 | Компьютерлар, электрон һәм оптик әйберләр җитештерү |

| | |
|---|---|
| 27 | Электр җиһазлары җитештерү |
| 28 | Башка төркемчәләргә кертелмәгән машиналар һәм җиһазлар җитештерү |
| 29 | Автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерү |
| 30 | Башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү |
| 31 | Җиһазлар җитештерү |
| 32 | Башка әзер әйберләр җитештерү»; |

8 бүлектә:

8.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Субсидияләр түбәндәгеләргә бирелә:

эшмәкәрлек субъектлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә Вәкаләтле органда аккредитация алган сәнәгать мәйданчыклары резидентларына, төбәк инжиниринг үзәкләре күрсәтә торган хезмәтләрдән файдаланучыларга, икътисадый эшчәнлекнең өстенлекле төрләрендә бизнес-проектлар тормышка ашыручы режимлы объектларның сәнәгать мәйданчыклары күрсәтә торган хезмәтләрдән файдаланучыларга җиһазлар сатып алуга бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен аларның фактта тотылган чыгымнарының иң күбе 50 проценты һәм бер алучыга иң күбе 5 млн.сум күләмендә;

эшмәкәрлек субъектлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә Вәкаләтле органда аккредитация алган бизнес-инкубаторлар резидентларына фактта тотылган чыгымнарының иң күбе 50 проценты һәм бер алучыга иң күбе 1 млн.сум күләмендә.

Субсидия алучы төбәк инжиниринг үзәкләре күрсәтә торган хезмәтләрдән файдаланучы булган очракта, ул гариза бирә торган эшчәнлек төре төбәк инжиниринг үзәге эшчәнлегенең профиленә туры килергә тиеш.»;

8.3 нче пунктта «2014 елның» сүзләрен «2015 елның» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.5. Җиһазлар сатып алуга бәйле булган чыгымнарның бер өлешен субсидияләү өчен эшмәкәрлек субъекты, бу Тәртипнең 4.1 нче пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны кертә:

җиһазларны милеккә сатып алу турында төзелгән шартнамәләр күчермәләрен (чит ил валютасында түләп, җиһазларны милеккә сатып алу турында чит ил

оешмалары белән төзелгән шартнамәләр күчермәләрен биргәндә әлеге шартнамәнең рус телендәге вариантын, шулай ук сатып алынган җиһазларның түләү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча сумнарда тулы кыйммәтен күрсәтеп, гариза бирүче җитәкчесе төзегән һәм кул куйган белешмәне теркәргә кирәк);

җиһазлар кайтартучы (сатучы) җиһазлар җитештерүченең җитештерүче продукциясен реализацияли торган рәсми дистрибьюторы, дилеры яки рәсми партнеры (вәкиле) булуны раслый торган документларның күчермәләрен;

түләү турында банк билгесе белән җиһазлар кыйммәтен тулысынча түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре һәм башка документлар күчермәләрен (чит ил валютасында түләгәндә, бенефициарның хисап исәбен, банкын һәм җиһазларның тулы кыйммәтен түләүне күрсәтеп, валюта күчерү буенча банк билгесе белән банк документларының тулы исемлеген кертергә кирәк) (булганда);

товар йөкнамәсе яки җиһазларны тапшыру-кабул итү акты күчермәсен (булганда);

Вәкаләтле орган раслый торган форма буенча бизнес-проект паспортын;

бизнес-проектны тормышка ашыруга кагыла торган документларны:

урыннары һәм җир кишәрлекләре булуны раслый торган документлар,

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның (булганда) күчермәләрен,

лицензияләр һәм рөхсәтнамәләр, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре нәтиҗәләре, эксперт бәяләмәләре һәм башкалар (булганда) күчермәләрен.»;

түбәндәге эчтәлекле $8.5^1$ – $8.5^4$ нче пунктлар өстәргә:

«$8.5^1$. Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары әлеге Тәртипнең 4.1 нче һәм 8.5 нче пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны кертә:

резидентның сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып баруы турында сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе белән төзелгән килешү күчермәсен яки гариза бирүче сәнәгать мәйданчыгы резиденты булуын раслый торган идарә итүче компания хаты (резидентлар реестрыннан өземтә);

субсидия бирелгән очракта, резидентның бер календарь елы эчендә җиһазларны сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнаштыру һәм алардан файдалану турындагы гарантияле хаты.

$8.5^2$. Режимлы объектларның сәнәгать мәйданчыклары резидентлары, әлеге Тәртипнең 4.1 нче һәм 8.5 нче пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе ведомствосы буйсынуындагы режимлы объектның сәнәгать мәйданчыгында бизнес-проект тормышка ашыручы эшмәкәрлек субъектын урнаштыру турында хат-хәбәрнамә кертә.

$8.5^3$. ТИҮ хезмәтләреннән файдаланучылар, әлеге Тәртипнең 4.1 нче һәм 8.5 нче пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны кертә:

профильле ТИҮ белән җитештерүне модернизацияләү, яңадан техник җиһазландыру һәм (яки) үстерү программасын эшләү хезмәтләре күрсәтүгә шартнамә күчермәсен һәм шартнамә кысаларында башкарылган эшләр акты;

житештерүне модернизацияләү, яңадан техник җиһазландыру һәм (яки) үстерү программасы.

8.5[4]. Бизнес-инкубаторлар резидентлары, әлеге Тәртипнең 4.1 нче һәм 8.5 нче пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, дәүләт мөлкәте арендасы шартнамәсе күчермәсен кертә.»;

8.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.6. Вәкаләтле оешмага түбәндәгеләрне тапшыру шарты белән төзелә торган шартнамә субсидия бирү өчен нигез булып тора:

милеккә җиһазлар сатып алу турында төзелгән шартнамәләр күчермәләрен (чит ил валютасында түләп, җиһазларны милеккә сатып алу турында чит ил оешмалары белән төзелгән шартнамәләр күчермәләрен биргәндә әлеге шартнамәнең рус телендәге вариантын, шулай ук сатып алынган җиһазларның түләү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча сумнарда тулы кыйммәтен күрсәтеп, гариза бирүче җитәкчесе төзегән һәм кул куйган белешмәне теркәргә кирәк);

түләү турында банк билгесе белән җиһазлар кыйммәтен тулысынча түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре һәм башка документлар күчермәләрен (чит ил валютасында түләгәндә, бенефициарның хисап исәбен, банкын һәм җиһазларның тулы кыйммәтен түләүне күрсәтеп, валюта күчерү буенча банк билгесе белән банк документларының тулы исемлеген кертергә кирәк);

товар йөкнамәсе яки җиһазларны тапшыру-кабул итү акты күчермәсен;

гариза бирүче җитәкчесе раслаган форма буенча әлеге җиһазларны балanska куюны раслый торган бухгалтерлык документлары (бухгалтерлык исәбе алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен);

җиһазларны сатып алу һәм тулысынча түләү фактын раслый торган керемнәр һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсе («Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 ел, 6 декабрь, ФЗ-402 нче Федераль закон нигезендә бухгалтерлык исәбе алып бармый торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен);

билгеләнгән тәртиптә таныкланган җиһазларны эксплуатациягә кертү турында документ;

сатып алына торган җиһазларның базар кыйммәтен билгеләү экспертизасы бәяләмәсен, шул ук вакытта әлеге бәяләмәне биргән юридик зат түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

алдагы ике ел эчендә кыйммәте кимендә 200 млн.сум торган проектлар буенча җиһазларның базар кыйммәтен билгели торган эксперт оешмасы буларак эш тәҗрибәсе булу;

товарларга экспертиза үткәрү һәм аларны тикшерүдә тоту өлкәсендәге гомуми эш тәҗрибәсе кимендә 5 ел тәшкил итү;

үз эшчәнлекләрен үзләре җайга сала торган бәя куючылар оешмасында әгъза булып тору.»;

түбәндәге эчтәлекле 8.7 нче – 8.10 нчы пунктлар өстәргә:

8.7. Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары, әлеге Тәртипнең 8.6 нчы пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе тарафыннан бирелгән, билгеләнгән тәртиптә таныкланган һәм резидентның сәнәгать

мәйданчыгы территориясендә җиһазлар урнаштыруын раслый торган хат-хәбәрнамә кертә.

8.8. Режимлы объектның сәнәгать мәйданчыгы резидентлары, әлеге Тәртипнең 8.6 нчы пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан бирелгән, билгеләнгән тәртиптә таныкланган һәм режимлы объектның сәнәгать мәйданчыгы территориясендә резидентның җиһазлар урнаштыруын раслый торган хат-хәбәрнамә кертә.

8.9. ТИҮ хезмәтләреннән файдаланучылар һәм бизнес-инкубаторлар резидентлары, әлеге Тәртипнең 8.6 нчы пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, бизнес-проектны торышка ашыру кысаларында җиһазлар урнаштыруны раслый торган документлар (фотохисап) кертә.

8.10. Субсидия бирү өчен документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган булырга тиеш, мөһер белән расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш, бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре эшмәкәрлек субъектының имзасы һәм мөһере (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта) белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\470.doc